РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БИЛЯР-ОЗЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БИЛЯР-ОЗЕРО
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Биляр-Озеро ав. КАРАР

«09» ноябрь 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Биляр - Озеро торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Биляр-Озеро авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 14 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Күл урамы, 1-1, Яшьләр урамы 1нче йорт, Садовая урамы1-54, Көнчыгыш урамы 1 - 16, Көнбатыш урамы 2 - 12, Зеленая урамы, 1 - 14 йортта яшәүче гражданнар өчен авыл үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 елның 15 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Спорт урамы 1- 41, Дорожная ур., 1-17, Южная ур., 1-23, Полевая ур. 1-26, Эшчеләр ур., 2-36, Овражный тыкрыгы 2нче йортта яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән

һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләр белән тәэмин итү эшләрен үткәрү;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен цистерна сатып алу;

- урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу».

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы И.М.Шәрәфетдинов